ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ-РӘҖӘП АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

08.10.2019ел №75-2

Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә
җирле әһәмияттәге мәсьәләләр
вәкаләтләрнең бер өлешен кабул итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, ТР Спас муниципаль район Советының «шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында" гы 07.10.2019 ел, № 42-4 карары нигезендә», Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Иске-Рәҗәп авыл җирлеге Советы карары белән «Спас муниципаль районы Иске-Рәҗәп авыл җирлеге җирле үзидарә органнары һәм ТР Спас муниципаль районы җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында " 2019 елның 16 июлендәге 70-2 номерлы Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Иске-Рәҗәп авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районынының шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрнең бер өлешен кабул итәргә:

- җирлекнең генераль планына үзгәрешләр кертү һәм раслау;;
- Җир биләмәләреннән файдалану һәм җирлек төзелеше кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү һәм раслау;;
- җирлекнең шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча җирле нормативларына үзгәрешләр кертү һәм раслау.

2. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Иске-Рәҗәп авыл җирлеге башкарма комитетына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы җирле үзидарә органнары белән тапшыру турында килешү төзүне тәэмин итәргә

3. Әлеге карарны Спас муниципаль районының http:// www. spasskiy.tatarstan.ru хокукый мәгълүмат рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) закон белән билгеләнгән срокта бастырып чыгарырга.

Иске-Рәҗәп авыл җирлеге башлыгы М.Ә.Нугаев